**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 2 сентябрь № 634

г. Казань

«Махсус санитар автотранспорт предприятиесе» Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениесен һәм «Ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү станциясе» сәламәтлек саклау дәүләт автоном учреждениесен үзгәртеп оештыру турында

Татарстан Республикасында дәүләт автоном учреждениеләр белән идарә итүне оптимальләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Махсус санитар автотранспорт предприятиесе» Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениесен һәм «Ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү станциясе» сәламәтлек саклау дәүләт автоном учреждениесен «Махсус санитар автотранспорт предприятиесе» Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениесен «Ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү станциясе» сәламәтлек саклау дәүләт автоном учреждениесенә кушу юлы белән, соңгысы эшчәнлегенең төп максатларын саклап, үзгәртеп оештыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. «Ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү станциясе» сәламәтлек саклау дәүләт автоном учреждениесе эшчәнлеген финанс ягыннан тәэмин итү әлеге максатларга тиешле финанс елына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасында күздә тотылган акча кысаларында гамәлгә ашырыла, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына 2016 елның 1 гыйнварына кадәр:

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән оешмаларны үзгәртеп оештыру белән бәйле, законнарда каралган чараларны үткәрүне тәэмин итәргә;

үзгәртеп оештыру чаралары нәтиҗәсендә эштән чыгарыла торган

хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне законнар нигезендә тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына:

«Ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү станциясе» сәламәтлек саклау дәүләт автоном учреждениесенең гамәлгә куючысы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашырырга;

билгеләнгән тәртиптә «Ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү станциясе» сәламәтлек саклау дәүләт автоном учреждениесе Уставына тиеше үзгәрешләр кертергә;

ел саен «Ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү станциясе» сәламәтлек саклау дәүләт автоном учреждениесе Уставында каралган төп эшчәнлек нигезендә аның өчен дәүләт биремен расларга.

5. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына «Ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү станциясе» сәламәтлек саклау дәүләт автоном учреждениесе Уставына кертелгән үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алганнан соң бер ай эчендә элек «Махсус санитар автотранспорт предприятиесе» Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениесенеке булган мөлкәтне «Ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү станциясе» сәламәтлек саклау дәүләт автоном учреждениесенә беркетергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\634.docx